РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» август 2019г. г. Альметьевск № 167

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 10 августындагы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә премияләр һәм башка естәмә түләүләр турындагы Нигезләмә хакында» 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль вазифаларны биләүче затларның хезмәт хакын түләү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында социаль гарантияләрне тәэмин итү, тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, 2001 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясе Хезмәт кодексы» 197-ФЗ номерлы, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 10 августындагы “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә премия бирү турындагы Нигезләмә хакында» 42 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 6 октябрендәге 48 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 61 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 121 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

1.1.1. 4 бүлектәге «Квартал премиясе» 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Квартал премияләре муниципаль хезмәткәрләргә киметелә:

- билгеләнгән күләмнән 10%ка - шәһәр башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, структур бүлек җитәкчесе йөкләмәләрен вакытында үтәмәгән һәм

сыйфатсыз башкарган ечен, гамәлдәге законнар нигезендә алар тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән, доклад язуы нигезендә;

- билгеләнгән күләмнән 15%ка - муниципаль программаларны башкаручыларга һәм җаваплы затларга, региональ һәм федераль программаларны үз вакытында һәм сыйфатлы итеп тормышка ашырмаган, яисә шәһәр бюджеты акчаларын нәтиҗәле һәм максатчан куллануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән аерым чараларны үз вакытында тормышка ашырмаган өчен;

- билгеләнгән күләмнән 25%ка – шәһәр башлыгы, шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенең ашыгыч һәм аеруча мөһим беркетмә йөкләмәләрен сыйфатсыз башкарган өчен, гамәлдәге законнар нигезендә алар тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән;

- билгеләнгән күләмнән 15%ка - кисәтүләр рәвешендә бер дисциплинар җәза булган очракта;

- билгеләнгән күләмнән 25%ка – кисәтүләр рәвешендә ике дисциплинар җәза булганда;

- шелтә рәвешендә дисциплинар җәза бирелгәндә түләнми»;

1.2. 4 бүлектәге «Квартал премиясе» 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Эш бирүче дисциплинар җәза кулланганнан соң ел узганчы хезмәткәрнең үз инициативасы, үзе үтенече һәм аның турыдан-туры җитәкчесе яисә хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы үтенече буенча төшереп калдырырга хокуклы.».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Бочкарев Н.А.).

Шәһәр башлыгы урынбасары А.М. Токарев

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»